КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2020 ел, 31 гыйнвар  г.Казань  № 65

1 000 кешегә хуҗасыз хайваннар
саны нормативы турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән саклау, шулай ук хайваннар белән эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Даими яшәүче 1 000 кешегә хуҗасыз хайваннар санының түбәндәге нормативын билгеләргә:

Татарстан Республикасы муниципаль районнары территориясендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясеннән тыш, – 2 баш;

«Казан шәһәре», «Чаллы шәһәре» шәһәр округлары һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре территорияләрендә – 2,8 баш.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин